РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

*Решение* *Карар*

от 17 апреля 2019 года г.Чистополь № 43/3

Чистай муниципаль районы
бюджетыннан алына торган
башка бюджетара трансфертлар
акчалары хисабына гамәлгә
ашырыла торган чыгымнар
юнәлешен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»гы 2010 ел, 28 март, 233 нче карары нигезендә һәм һөнәри керемгә салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында, Чистай муниципаль районы Советы

Карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы составына керүче җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә, Чистай муниципаль районы рәсми сайтында: http://chistopol.tatar.ru/, Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүмат интернет-порталында: pravo.tatarstan.ru урнаштыруны йөкләргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы Советының бюджет-финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы башлыгы Д.А.Иванов

2019 елның 17 апрелендәге
Чистай муниципаль район Советының №43/3 карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы составына керүче җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы составына керүче җирлекләр бюджетларына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар, муниципаль берәмлекләр) бирү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасында профессиональ керемгә салым буенча салым потенциалы үсешен стимуллаштыру максатларында Чистай муниципаль районы составына керүче җирлекләр бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бирелә.

3. Һәр квартал саен өч эш көне дәвамында Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюдңетара трансфертлар җирлекләр бюджетларына күчерелә.

4. Башка бюджетара трансфертларның бүленүе һәм күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5. Җирлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү өчен, билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән тотыла торган чыгымнарның юнәлешен билгели торган җирлек актының булуы шарт.

6. Җирлекләрнең Башкарма комитетлары (алга таба – җирлек Башкарма комитетлары) Чистай муниципаль районы финанс-бюджет палатасына форма буенча һәм финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап.

7. Агымдагы финанс елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар, әлеге Тәртип нигезендә агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Финанс-бюджет палатасы тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турында карар нигезендә әлеге башка бюджетара трансфертларның калдыкларыннан артмаган күләмдә акчалар агымдагы финанс елында җирлек бюджеты кеременә кире кайтарылырга мөмкин, моңа кадәр алар бирелгән җирлек бюджеты чыгымнарын финанс ягыннан тәэмин итү өчен, әлеге башка бюджетара трансфертлар бирүнең тиешле максатларына туры килә торган җирлек бюджеты кеременә кире кайтарылырга мөмкин.

Әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыклары Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акчалар Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы бюджеты кеременә Россия Федерациясе Фи-

нанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.

8. Җирлекләр Башкарма комитетлары һәм вазыйфаи затлар законнар нигезендә тапшырыла торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлар бирү шартларын үтәү өчен җаваплы.

9. Башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта, тиешле акчалар Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы бюджеты кеременә Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

10. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы финанс-бюджет палатасы гамәлгә ашыра.